ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«10» март 2023 ел № 50

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы территориясендә 2023 елның янгын куркынычы сезонына урманнарны янгыннан кисәтү һәм саклау чаралары турында

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы территориясендә урманнарны янгын куркынычы сезонына янгыннардан кисәтү һәм саклау эшен оештыру максатларында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, Россия Федерациясе Урман кодексының 84 маддәсе нигезендә, «Әгерҗе урманчылыгы» ДКУның 06.03.2023 елның 10 номерлы «2023 елның янгын куркынычы сезонына карар турында» хатын карап чыгып, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы территориясендә урманнардан файдаланучы затларга Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы территориясендә урманнарда янгын куркынычсызлыгы чараларын үтәүне тәэмин итәргә тәкъдим итәргә.

2. Тәкъдим итәргә:

2.1. Авыл җирлекләре башлыкларына, крестьян-фермер хуҗалыклары башлыкларына, учреждениеләр, предприятиеләр, оешмалар җитәкчеләренә, милек формасыннан бәйсез рәвештә, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Урманнарда янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрен раслау турында " 07.10.2020 елның 1614 номерлы карарында каралган урманнарда янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрен үтәүне тәэмин итү буенча чаралар күрергә, атап әйткәндә:

кар катламы төшкән көннән алып көзге тотрыклы яңгырлы һава торышы яисә кар япмасы барлыкка килгәнче аны урманнан кимендә 10 метр киңлектәге полосада кипкән үләнчел үсемлекләрдән, корыган үләннәрдән, киселгән калдыклардан, чүп-чардан һәм башка төрле янучан материаллардан чистартуны тәэмин итәргә яки урманны кимендә 1,4 метр киңлектәге янгынга каршы минераллаштырылган полоса яисә янгынга каршы башка барьер белән аерып алырга.

2.2. Россия Эчке эшләр министрлыгының Әгерҗе районы буенча бүлеге башлыгына Урман хуҗалыгы хезмәткәрләренә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы территориясендә урнашкан урманнарда янгын

куркынычсызлыгы кагыйдәләрен бозучыларга каршы көрәштә һәм профилактик чаралар үткәрүдә кирәкле ярдәм күрсәтергә.

3. Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районынын авыл җирлекләре башлыкларына урман фондына тоташкан торак пунктларны, янгынга каршы су белән тәэмин итү, су башняларын янгын сүндерү автомобильләре белән су алу җайланмалары белән тәэмин итү, ясалма сулыклар һәм аларга килү юллары урнаштыру, урман массивларына тоташкан торак пунктлар чикләре буйлап минераллаштырылган полосалар уздыру, урманнарда янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрен үтәү буенча халыкка мәгълүмат бирү чараларын күрергә.

4. Авыл хуҗалыгы оешмалары һәм аларның филиаллары, крестьян-фермер хуҗалыклары җитәкчеләренә:

4.1. Янгынга каршы техника һәм инвентарь белән тәэмин ителгән ирекле янгын сүндерү формированиеләрен булдырырга.

4.2. Урман янгыннарын сүндерү планнарына (оператив (мобилизацион) планнарга)ярашлы рәвештә урман янгыннарын сүндерү өчен көч һәм чаралар бүлеп бирүне тәэмин итәргә.

4.3. Урман янгыннарына каршы көрәшкә җәлеп ителә торган затларны хәрәкәт итү чаралары, туклану һәм медицина ярдәме белән тәэмин итүдә ярдәм күрсәтергә.

5. “Татмедиа” АҖ филиалы - Әгерже районы “Әгерже хәбәрләре” газетасы редакциясе белән берлектә, үткәрелә торган чаралар һәм проблемалы мәсьәләләр турында, торак пунктларның янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча оператив хәлләр хакында массакүләм мәгълүмат чараларында яктырту, шулай ук язгы-җәйге чорда янгын куркынычсызлыгы чаралары турында халыкка мәгълүмат җиткерергә.

6. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерже муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (https://agryz.tatarstan.ru).

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүне Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Р. Р. Шәриповка йөкләргә

**Җитәкчесе** **Л.Ф. Нургаянов**